ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**V чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**V созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
04.03.2026 ел

**РЕШЕНИЕ**
№06-07

## Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 декабрендәге 13-06 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 13-06 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.8.1 пунктның 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләре, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үз-үзен җайга салучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов